КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 май г.Казань № 308

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Сәнәгать (индустриаль) парkларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 4 июль, 548 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 4 июль, 548 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 18 декабрь, 1162 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 июль, 548 нче карары белән расланган Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны

финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2020 ел, 30 май, 442 нче;

«2020 елда идарәче компанияләргә һәм (яисә) сәнәгать (индустриаль) парклар, сәнәгать мәйданчыклары резидентларына аларның инфраструктурасын үстерүгә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру өчен «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 2 октябрь, 894 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин